РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«26» июня 2024 г. г. Альметьевск № 300

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 91 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контролЬ турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 январендагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 05 февралендәге 124 номерлы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы карары нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 91 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 16 декабрендәге 111 номерлы, 2023 елның 6 июлендәге 231 номерлы, 2023 елның 2 ноябрендәге 259 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 кушымтада:

- 1 нче бүлекнең 1.7 пункты 1 нче пунктчасы «(шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы),» сүзләреннән соң «яр буе,» сүзе белән тулыландырырга;
- 6.12 пунктының 1 пунктчасында «5.4 пункты белән» сүзләрен «6.4 пункты» сүзләре белән алыштырырга;
- 6.13 пунктта «5.12 пункты» сүзләрен «6.12 пункты» сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында»

(PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан (халыкка игълан ителгәннән соң) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, салымнар һәм җыемнар, икътисади үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов